ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИЖНЕКОНДРАТИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН КОНДРАТА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422973, Республика Татарстан,
Чистопольский район, д. Нижняя Кондрата,
ул. Комсомольская, 29

422973, Татарстан Республикасы,
Чистай районы, Түбән Кондрата авылы,
Комсомол урамы, 29

тел: 8(84342) 3-06-74 E-mail: Nkondr.Ctp@tatar.ru

Постановление Карар

2020 елның 30 апреле № 11

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Түбән Кондрата авыл җирлеге Башкарма
комитетының “Чистай муниципаль районы
Түбән Кондрата авыл җирлеге җирле
үзидарә органнары тарафыннан
муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең
административ регламентларын эшләү
һәм раслау тәртибен раслау турында”гы
2019 елның 20 декабрендәге 11 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү хакында”

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә Чистай муниципаль районының Түбән Кондрата авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. “Чистай муниципаль районы Түбән Кондрата авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенең 1.2 пунктына “Чистай муниципаль районы Түбән Кондрата авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау турында”гы Чистай муниципаль районы Түбән Кондрата авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 20 декабрендәге 11 номерлы карары белән түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“административ регламент - дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен һәм дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү стандартын билгели торган норматив хокукый акт;”;
1.2 пунктының 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“муниципаль хезмәт - җирле үзидарә органы функцияләрен гамәлгә ашыру эшчәнлеге мөрәҗәгать итүчеләр соравы буенча “Россия Федерациясендә җирле

үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы һәм муниципаль берәмлек уставы нигезендә, шулай ук күрсәтелгән Федераль Законда җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә каралган хокуклары чикләрендә җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүче орган вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашырыла (күрсәтелгән Федераль законның 19 статьясы нигезендә аларга тапшырылмаган) башка дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу өчен җирле үзидарә органнарының федераль законнарда башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары компетенциясенә кермәгән һәм федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектлары законнары белән мондый хокукларны гамәлгә ашыру турында муниципаль хокукый актлар кабул ителгән очракта аларның компетенциясеннән төшереп калдырылмаган башка мәсьәләләрне хәл итү хокукы каралган булса;”.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында яисә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Түбән Кондрата авыл җирлеге
башлыгы С. В. Васильев